ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 апрель, 2016 ел № 7/18

Вазифаларны үтәгәндә мәнфәгатьләр
каршылыгына китерүче яисә китерергә
мөмкин булган шәхси кызыксынганлык
барлыкка килү хакында хәбәр итү
тәртибе турында нигезнамәне раслау
хакында

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон, РФ Президентының 2015 елның 22 декабрендәге «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазифаларын, федераль дәүләт хезмәте вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның вазифаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлыгы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» УП-650 санлы Указы, ТР Президентынң 2016 елның 18 мартындагы «Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазифаларын биләүче затларның вазифаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлыгы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында, һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» УП-265 санлы Указы, шәһәр Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Вазифаларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлык барлыкка килү хакында хәбәр итү тәртибе турында нигезнамәне кушымтадагыча расларга.

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
7/18 нче Карарына кушымта
7 апрель, 2016 ел

Вазифаларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлык барлыкка килү хакында хәбәр итү тәртибе турында нигезнамә

1. Әлеге Нигезнамә белән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советында муниципаль вазифалар биләүче затларның вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе билгеләнә.

2. Муниципаль вазифалар биләүче затлар Россия Федерациясенең коррупциягә каршы көрәшү турында законнары нигезендә вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлык барлыкка килү турында хәбәр итәргә, шулай ук мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш.

Хәбәр язмача, вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлык барлыкка килү турында хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) рәвешендә рәсмиләштерелә.

3. Муниципаль вазифалар биләүче затлар шәһәр Хакименә кушымта нигезендәге форма буенча төзелгән хәбәрнамә җибәрәләр.

4. Шәһәр Хакиме исеменә килгән хәбәрнамәләр карау өчен Керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларның дөреслеген контрольдә тоту буенча Шәһәр Советы комиссиясенә тапшырыла.

Хәбәрнамәләрне алдан карап тикшерү барышында Комиссия секретаре хәбәрнамә җибәргән затлардан анда бәян ителгән хәлләр буенча билгеләнгән тәртиптә аңлатмалар сорарга һәм дәүләт хакимиятенең федераль органнарына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимяте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга билгеләнгән тәртиптә соратулар җибәрергә хокуклы.

5. Хәбәрнамәләрне алдан карап тикшерү нәтиҗәләре буенча аларның һәрберсенә дәлилле бәяләмә әзерләнә.

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында алынган хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар, Комиссиягә хәбәрнамәләр кергән көннән алып, җиде эш көне эчендә Комиссия утырышында тәкъдим ителә.

Әлеге Нигезнамәнең 4 пункты икенче абзацында күрсәтелгән соратулар җибәрелгән очракта, хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар, хәбәрнамәләр шәһәр Хакименә кергән көннән алып, 45

көн эчендә Комиссиягә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озынайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә артмаска тиеш.

6. Комиссия хәбәрнамәләрне карый, алар буенча карарлар кабул итә һәм кабул ителгән карарны шәһәр Хакименә юнәлтә.

7. Шәһәр Хакиме тарафыннан Комиссиянең хәбәрнамәләрне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

а) хәбәрнамә җибәргән зат вазифаи бурычларын үтәгәндә, мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килми;

б) хәбәрнамә җибәргән зат вазифаи бурычларын үтәгәндә, шәхси кызыксынганлыгы мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яисә китерергә мөмкин, дип танырга;

в) хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу һәм (яки) җайга салу буенча чаралар күрелмәгән, дип танырга.

8. Әлеге Нигезнамәнең 7 пункты «б» пунктчасында билгеләнгән карар кабул ителгән очракта, шәһәр Хакиме Россия Федерациясе законнары нигезендә мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрә яки чаралар күрүне тәэмин итә яисә хәбәрнамә җибәрән затка шундый чаралар күререгә тәкъдим итә.

9. Әлеге Нигезнамәнең 7 пункты «в» пунктчасында билгеләнгән карар кабул ителгән очракта, шәһәр Хакиме Россия Федерациясе законнарында каралган юридик җаваплылык чараларын куллана.

Вазифаларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлык барлыкка килү хакында хәбәр итү тәртибе турында нигезнамәгә кушымта

______________________________
(документ белән танышу турында билге)

Яр Чаллы шәһәре Хакименә
______________________________
(Ф.И.А.и., вазифасы)

Вазифаларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлык барлыкка килү хакында
хәбәрнамә

Вазифаларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлык барлыкка килү хакында хәбәр итәм (тиешлесенең астына сызарга).

Шәхси кызыксынганлык барлыкка килүгә нигез булып торучы шартлар: __________________________________________
____________________________________________________

Шәхси кызыксынганлык йогынты ясый торган яки йогынты ясарга мөмкин булган бурычлар: ______________________________
____________________________________________________

Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яисә җайга салу буенча тәкъдим ителүче чаралар: ___________________________________
____________________________________________________

Вазифаларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлык барлыкка килү хакында Шәһәр Советы комиссиясе утырышында әлеге хәбәрнамәне карау барышында шәхсән катнашырга ниятлим (ниятләмим) (тиешлесенең астына сызарга).

«____» __________20__ ел. _________________________ __________
(хәбәрнамә җибәргән затның имзасы (имзаны шәрехләү)